РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

11.08.2025 №602-п

«Саба муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау хакында» Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 10 сентябрендәге 735-п номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2025 елның 28 февралендәге 7-ТРК номерлы Татарстан Республикасы Кануны кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Саба муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау турында» Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 нче елның 10 сентябрендәге №735-п номерлы карарына (№ 1105-п 26.12.2024 ел, №191-п 17.03.2025 ел редакциясендә) яңа редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе М.Р. Ишниязовка йөкләргә.

Җитәкче М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының
"______" ____________20_____г. №________
карарына КУШЫМТА

**Беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге**
**Саба муниципаль районында административ хокук бозулар турында**

| *ТР Административ хокук бозулар кодексы статьялары* | *Вазыйфаи затлар исемлеге* |
|---|---|
| **АХБт ТРК сының 2.1 статьясы**<br>Телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозу (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешманың элмә тактада үз исемен һәм элмә тактага урнаштырылырга тиешле башка мәгълүматларны күрсәткәндә, телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуга карата) | - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге әйдәп баручы белгече;<br>- Саба муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге баш белгече. |
| **АХБт ТРК сының 2.4 статьясы**<br>Татарстан Республикасы дәүләт символларына карата законсыз гамәлләр | - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге әйдәп баручы белгече. |
| **АХБт ТРК сының 2.5 статьясы**<br>Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен законсыз әзерләү яисә тагып йөрү | - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге әйдәп баручы белгече. |
| **АХБт ТРК сының 2.6 статьясы**<br>Җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларын үтәмәү<br>**АХБт ТРК сының 2.7 статьясы**<br>Муниципаль берәмлекләрнең рәсми символларыннан файдалану тәртибен бозу | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Юридик бүлеге башлыгы;<br>- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге әйдәп баручы белгече. |
| **АХБт ТРК сының 2.12 статьясы**<br>Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен бозу<br>**АХБт ТРК сының 2.13 статьясы**<br>Социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алу һәм исәпкә алу тәртибен бозу | - Саба муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы һәм террорчылыкка каршы мәсьәләләр буенча ярдәмчесе;<br>- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге әйдәп баручы белгече. |
| **АХБт ТРК сының 2.15 статьясы** | - Саба муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы һәм террорчылыкка каршы мәсьәләләр буенча ярдәмчесе; |

| | |
|---|---|
| Терроризмны профилактикалау, аның чагылышларын минимальләштерү һәм (яисә) бетерү буенча коллегиаль органның карарын үтәмәү яисә бозу | |
| **АХБт ТРК сының 2.17 статьясы**<br>Яңа коронавирус йогышлы авыруының (COVID-19) таралуын булдырмый калуга һәм бетерүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү. | - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге әйдәп баручы белгече. |
| **АХБт ТРК сының 2.21 статьясы**<br>Режим кысаларындагы (база әзерлеге дәрәҗәсендәге) чараларны гамәлгә ашыруны күздә тоткан Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү | - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге әйдәп баручы белгече; |
| **АХБт ТРК сының 2.22 статьясы**<br>Балигъ булмаганарга автомобиль бензинын ваклап сатуны чикләүне үтәмәү | - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге әйдәп баручы белгече; |
| **АХБт ТРК сының 3.2 статьясы**<br>Урамда сәүдә оештыру һәм халыкның күңел ачуларына бәйле хезмәтләр күрсәтү тәртибен бозу.<br>**АХБт ТРК сының 3.5 статьясы**<br>Тышкы мәгълүматны урнаштыру тәртибен бозу | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге баш белгече;<br>- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге әйдәп баручы белгече. |
| **АХБт ТРК сының 3.3 статьясы**<br>Җир асты коммуникацияләрен карап тоту кагыйдәләрен бозу<br>**АХБт ТРК сының 3.4 статьясы**<br>Урам, квартал эчендә яктыртуны карап тоту кагыйдәләрен бозу<br>**АХБт ТРК сының 3.6 статьясы**<br>Җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерү буенча муниципаль кагыйдәләрне, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләрен бозу<br>**АХБт ТРК сының 3.17 статьясы**<br>Яшелләндерелгән территорияләрдә, балалар һәм спорт мәйданчыкларында, хайваннарны йөртү мәйданчыкларында, шулай ук йорт яны территориясендә урнашкан хуҗалык мәйданчыкларында транспорт чараларын урнаштыру | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы урынбасары<br>- Саба муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече;<br>- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге әйдәп баручы белгече. |
| **АХБт ТРК сының 3.8 статьясы**<br>Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозу | - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге әйдәп баручы белгече. |

| | |
|---|---|
| **АХБт ТРК сының 3.10 статьясы**<br>Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрен бозу | - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге әйдәп баручы белгече. |
| **АХБт ТРК сының 3.11 статьясы**<br>Балаларның сәламәтлегенә һәм аларның үсешенә зыян китерүне кисәтү чараларын тәэмин итүгә карата таләпләр булмау | - Саба муниципаль районы башкарма комитеты балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең баш белгече;<br>- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге әйдәп баручы белгече;<br>- Саба муниципаль районы башкарма комитеты балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең әйдәп баручы белгече. |
| **АХБт ТРК сының 3.14 статьясы**<br>Мәдәни-тамаша чараларында булганда җәмәгать тәртибен бозу | - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге әйдәп баручы белгече. |
| **АХБт ТРК сының 3.15 статьясы**<br>Җәмәгать урыннарында гражданнарга бәйләнү | - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге әйдәп баручы белгече. |
| **АХБт ТРК сының 3.15[1] маддәсе**<br>Иҗтимагый урыннарда товарлар һәм хезмәтләр күрсәтү | - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге әйдәп баручы белгече. |
| **АХБт ТРК сының 3.16 статьясы**<br>Түләүле муниципаль парковкада (парковка урыннарында) транспорт чараларын урнаштырган өчен түләмәү | - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге әйдәп баручы белгече. |
| **АХБт ТРК сының 3.19 статьясы**<br>Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдалану тәртибенә карата таләпләрне бозу | - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге әйдәп баручы белгече. |
| **АХБт ТРК сының 4.4 статьясы**<br>Муниципаль милектәге торак булмаган фонд объекты белән эш итү һәм күрсәтелгән объекттан файдалану тәртибен бозу | - Саба муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының баш белгече;<br>- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге әйдәп баручы белгече. |
| **АХБт ТРК сының 5.1 статьясы**<br>Билетсыз йөрү<br>**АХБт ТРК сының 5.2 статьясы**<br>Багаж йөртү кагыйдәләрен бозу | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы урынбасары;<br>- Саба муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече; |

| | |
|---|---|
| **АХБт ТРК сының 5.6 статьясы**<br>Пассажирга юл бирүдән баш тарту | - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге әйдәп баручы белгече. |